# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Саурыш авыл җирлеге составына керүче Васильевка торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында.

2019 елның 28 ноябре № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлегендә Васильевка торак пунктында (поселогы) халык җыены карар итте:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районы Саурыш авыл җирлеге Васильевка торак пункты (поселогы) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан һәм көндезге формада укучы студентлардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

**1.Җирлек торак пунктлары чикләрендә, шул исәптән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

1). Васильевка торак пунктында (поселогы) вак таш җәелгән юлларны ремонтлау.

2).Васильевка поселогында урамнарны карап тоту.

**2.Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны да кертеп).**

1). Васильевка поселогында урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

**3. Оештыру ритуаль хезмәтләр һәм карап тоту урыннар күмү.**

1). Васильевка поселогында зират коймаларын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Саурыш авыл җирлеге башлыгы: А. Г. Кузьмин